Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлегендә гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында КАРАР

2020 елның 27 ноябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 27 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирдовский Каратай авылы җирлегендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм 1 төркем инвалидлардан тыш,500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- авыл эчендәге һәм урам ара юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (шартнамә буенча эшләр өчен түләү, вак таш сатып алу, кайтарту , вак таш җәю, тигезләү);
- җәйге-көзге чорда чүп үләннәрне чаптыру (килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
-юлларны кышкы тәртиптә тоту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 48 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 26 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенының 26 катнашучысы тавыш бирде;
"Юк" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы составына керә торган Кирельский авыл җирлегенең Мордва Каратае авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Мордва Каратае авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм 1 төркем инвалидларыннан тыш, 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме?соравы буенча карар кабул итәргә.

- авыл эчендәге һәм урам ара юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (шартнамә буенча эшләр өчен түләү, вак таш сатып алу, кайтарту , вак таш җәю, тигезләү);

- җәйге-көзге чорда чүп үләннәрне чаптыру (килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- кабул ителгән юлларны кышкы тәртиптә тоту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)».

3. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Мордва Каратае авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм 1 төркем инвалидлардан тыш, үзара салым суммасын 500 сум кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- авыл эчендәге һәм урам ара юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (шартнамә буенча эшләр өчен түләү, вак таш сатып алу, кайтарту , вак таш җәю, тигезләү);

- җәйге-көзге чорда чүп үләннәрне чаптыру (килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

-юлларны кышкы тәртиптә тоту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Мордва Каратае авылы, Үзәк ур., 7 й., шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Кирельский
авыл җирлеге башлыгы, Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
районының Кирельский авыл җирлеге
Советы рәисе, җыенда рәислек итүче Ф.Я. Зиннәтуллин